ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
20 декабрь 2023ел.

**КАРАР**
№ 84

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслау турындагы 2021 елның 17 декабрендәге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Башкарма комитетының» карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитеты Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.2 пунктының дүртенче абзацына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслау турында» 17.12.2021 ел, № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәреш кертергә, аны яңа редакциядә, №1 кушымтага ярашлы рәвештә, бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеттан башлап Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев

Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитетының 20.12.2023 ел, № 84 карарына 1 нче кушымта

Пыжмара авыл җирлеге бюджет керемнәренең Баш администраторлары Исемлеге

| Бюджет классификациясе коды | | Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторының иceме /Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре төренең (подвидының) коды исеме / Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторы | Төр (подвид) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре Татарстан | |
| **097** | **Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы** | |
| 097 | 1 11 01050 10 0000 120 | Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (склад) капиталындагы өлешләргә туры килгән табыш яки авыл җирлекләренә караган акцияләр буенча дивидендлар рәвешендә керем |
| 097 | 1 11 02085 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге акцияләрне сату буенча аукционнар үткәрү барышында туплана торган суммаларны урнаштырудан кергән керемнәр |
| 097 | 1 11 05025 10 0000 120 | Аренда хакы рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук авыл җирлекләре милкендә булган җирләр өчен аренда килешүләре төзү хокукын сатудан кергән акчалар (муниципаль бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең җир участокларыннан тыш) |
| 097 | 1 11 05026 10 0000 120 | Авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда хакы рәвешендә алына торган керемнәр Федераль милектә һәм идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләрен арендалау килешүләрен төзү хокукын сатудан кергән акчалар |
| 097 | 1 11 05027 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосада урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда хакы рәвешендә алына торган керемнәр |
| 097 | 1 11 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнарының һәм алар төзегән учреждениеләрнең (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр милкеннән тыш)оператив идарәсендә булган |

| | | |
|---|---|---|
| | | мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 097 | 1 11 07015 10 0000 120 | Салымнар һәм авыл җирлекләре тарафыннан төзелгән муниципаль унитар предприятиеләрнең башка мәҗбүри түләүләреннән соң калган табышның бер өлешен күчерүдән кергән керемнәр |
| 097 | 1 11 08050 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казен предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышаныч идарәсенә тапшырудан алынган акчалар |
| 097 | 1 11 09045 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендә булган мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна мөлкәтеннән тыш)файдаланудан башка керемнәр |
| 097 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән(эшләрдән) башка керемнәр |
| 097 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керүче керемнәр |
| 097 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 097 | 1 14 01050 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге фатирларны сатудан кергән керем |
| 097 | 1 14 02050 10 0000 410 | Күрсәтелгән мөлкәт буенча төп средстволарны сату өлешендә авыл җирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм Автоном учреждениеләрнең күчемле мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләрнең, шул исәптән казеннарның мөлкәтеннән тыш) сатудан кергән керемнәр |
| 097 | 1 14 02050 10 0000 440 | Күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны сату өлешендә авыл җирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна мөлкәтеннән тыш) сатудан кергән керемнәр |
| 097 | 1 14 02052 10 0000 410 | Авыл җирлекләре идарәсе органнары карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендә булган мөлкәтне сатудан кергән керемнәр (муниципаль бюджет һәм автономияле учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) күрсәтелгән мөлкәт буенча төп средстволарны сату өлешендә |